Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа поселогы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«12» декабрь 2021 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Әҗмәкәй авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. « Әҗмәкәй авыл җирлегенең Яңа поселогы территориясендә 2022 елда балигъ булган, Әҗмәкәй авыл җирлегенең Яңа поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, Әфганстанда, Чечняда сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, чернобыльчеләр-ЧАЭСТА авария ликвидаторлары, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

1) юлларны ремонтлау;

2) балалар уен мәйданчыгын сатып алу һәм урнаштыру;

3) зиратны төзекләндерү (христиан зиратының киңәйтелгән өлешен койма алу һәм урнаштыру)

4) электр материаллары сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру.

2. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа поселогыгражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Яңа поселогыгражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әҗмәкәй авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Адиев